**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Зур Әтрәч авыл җирлегенең Никифоровка торак пунктында булган ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**27 .11. 2020** **№ 2**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 56, 25.1 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Зур Әтрәч авыл җирлегенең Никифоровка торак пунктында булган гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Зур Әтрәч авыл җирлегенең Никифоровка торак пункты территориясендә, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, балачактан инвалид, күп балалы гаиләләр һәм көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан һәм Россия Федерациясенең армия сафларында хезмәттә булучылардан кала, Тәтеш муниципаль районы Зур Әтрәч авыл җирлегенең Никифоровка торак пункты территориясендә яшәү урыны буларак теркәлгән һәр балигъ булган гражданнан үзара салымга 1200 сум күләмендә акча җыелуны кертергә.

2. гражданнарның үзара салым акчаларын түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне чишү өчен юнәлдерергә:

- Зират территориясен төзекләндерү;
- Суэтем каланчасына тирәнлек насосын сатып алу һәм урнаштыру;
- Декабристлар урамындагы 41 номерлы йорт янындагы сууткәргечне ремонтлау;
- Сугышта һәлак булганнар истәлегенә куелган һәйкәлне ремонтлау;
- Сугышта һәлак булганнар истәлегенә куелган һәйкәл территориясендәге коймаларны ремонтлау.

3. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы”нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырып халыкка җиткерергә.

**Гражданнар җыенында<br>рәислек итүче,<br>Татарстан Республикасы<br>Тәтеш муниципаль районы<br>Зур Әтрәч авыл җирлеге<br>башлыгы** **И.Ш. Юнысов**